**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**24 нче июль 2020 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 44**

## Биектау муниципаль районында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турындагы Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясы, 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар үтәлешен ведомство контролен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр тапшырырга.

3. «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына:

2020 елга ведомствога караган оешмаларны тикшерү буенча еллык планны эшләргә һәм расларга;

2020 елга ведомствога караган оешмаларны тикшерү буенча еллык планны Биектау муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында урнаштырырга;

хезмәт законнарын үтәү буенча ведомство контролен үткәрүнең нәтиҗәлелеген ел саен анализларга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Р.Г.Кәлимуллин

1 нче кушымта
Расланды
Биектау муниципаль районы
Башлыгының 2020 елның
"24"июль 2020 ел
44 нче номерлы карары белән

# ХЕЗМӘТ ЗАКОННАРЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ХОКУКЫ НОРМАЛАРЫН ҮЗ ЭЧЕНӘ АЛГАН БАШКА НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ҮТӘЛЕШЕНӘ ВЕДОМСТВО КОНТРОЛЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Җайга салу предметы

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясы, 2019 елның 27 ноябрендәге 100-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән, Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба - җирле үзидарә органы) буйсынуындагы оешмаларда, хезмәт законнарының һәм башка хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп тору тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә карата хезмәт законнарының үтәлешен тикшерү «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының вәкаләтле хезмәткәрләре (алга таба - вәкаләтле вазыйфаи затлар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.2. Ведомство контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

## II. Төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле (алга таба - ведомство контроле) - җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларда тикшерүләр оештыру һәм үткәрү юлы белән башкарыла торган хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозуларны кисәтүгә, ачыклауга һәм булдырмауга юнәлдерелгән эшчәнлеге;

ведомство буйсынуындагы оешмалар - гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен җирле үзидарә органы гамәлгә ашыра торган оешмалар;

тикшерү - җирле үзидарә органының үз буйсынуындагы оешмаларга карата алар гамәлгә ашыра торган эшчәнлекнең хезмәт законнары таләпләренә һәм хезмәт хокукы нормалары үз эченә алган башка норматив хокукый актларга туры килүен бәяләү өчен үткәрелә торган ведомство контроле буенча чаралар җыелмасы.

## III. Ведомство контролен оештыру

3.1. Ведомство контроле җирле үзидарә органы тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерүләр буларак гамәлгә ашырыла.

3.2. Тикшерүләр документар һәм (яисә) күчмә (урынга чыгып) рәвештә үткәрелә.

3.3. Тикшерүләр җирле үзидарә органының түбәндәге белешмәләрне үз эченә алырга тиешле хокукый акты нигезендә үткәрелә:

1) тикшерү үткәрә торган органның исеме;

2) тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булган очракта) һәм вазыйфалары;

3) тикшерү үткәрелә торган ведомство буйсынуындагы оешманың исеме, ведомство буйсынуындагы оешманың урнашкан урыны һәм (яисә) аның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны;

4) тикшерү формасы һәм төре;

5) тикшерү үткәрүгә нигезләр;

6) тикшерү үткәрү өчен ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан бирелергә тиешле документлар исемлеге;

7) тикшерү башлану датасы һәм аны уздыру вакыты.

3.4. Тикшерүне уздырганда вазыйфаи затлар тикшерүне үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән шәхси мәгълүматларны, белешмәләрне, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, таратырга хокуксыз.

3.5. Ведомство контролен уздырганда вазыйфаи затлар Росхезмәтнең 2017 елның 10 ноябрендәге 655 нче номерлы «Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүгә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлекләре) формаларын раслау турында» боерыгы белән расланган хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүне тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга хокуклы.

## IV. Планлы тикшерүләрне оештыру

4.1. Планлы тикшерү предметы булып, ведомство карамагындагы оешмалар тарафыннан хезмәт законнары таләпләрен һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәү тора.

4.2. Планлы тикшерүләр җирле үзидарә органы тарафыннан планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – еллык план) нигезендә өч елга бер тапкырдан ешрак булмаган санда үткәрелә (1 нче кушымта).

4.3. Еллык план җирле үзидарә органының хокукый акты белән планлы тикшерүләр уздырыласы елдан алдагы елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча раслана һәм аны раслаган көннән соң 10 көн эчендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла. Еллык планда күрсәтеләләр:

1) тикшерү үткәрелергә тиешле ведомство буйсынуындагы оешмаларның

исеме, аларның урнашкан урыны һәм (яисә) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны;

2) һәр планлы тикшерүне башлауның датасы һәм аны уздыру сроклары.

4.4. Ведомство буйсынуындагы оешманы еллык тикшерү планына кертү өчен нигез булып ведомство буйсынуындагы оешманы дәүләт теркәвенә алган көннән яисә ведомство буйсынуындагы оешманы соңгы планлы тикшерү уздыру тәмамланган көннән өч ел узу тора.

4.5. Планлы тикшерү үткәрү турында ведомствога караган оешмага планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан, аны үткәрә башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

## V. Планнан тыш тикшерүләрне оештыру

5.1. Планнан тыш тикшерү предметы булып ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәү һәм элек үткәрелгән тикшерү барышында ачыкланган бозуларны бетерү тора.

5.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора:

1) хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозуларны элегрәк тикшерү буенча актта күрсәтелгән хокук бозуларны тиешле срокта бетермәү;

2) җирле үзидарә органына гражданнар, оешмалардан мөрәҗәгатьләр, гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозу фактлары турында мәгълүмат керү.

5.3. Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозу фактлары турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

5.4. Җирле үзидарә органы планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар кабул итә:

1) элек үткәрелгән тикшерү барышында хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозуны бетерү өчен вакыт тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә;

2) әлеге статьяның 2 бүлегенең 2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать, гариза, мәгълүмат килгән көннән алып 30 көн эчендә.

5.5. Планнан тыш тикшерү үткәрү турында ведомство буйсынуындагы оешма җирле үзидарә органы тарафыннан, тикшерү үткәрү башланганчы 24 сәгать алдан, тикшерү үткәрү турында күрсәтмә (аның күчермәсе) җибәрү юлы белән әлеге документның чынлыкта тапшырылуын дөрес билгеләргә мөмкинлек бирә торган теләсә нинди мөмкин булган ысул белән хәбәр ителә.

## 3.3. VI. Документар тикшерү үткәрү

6.1. Документар тикшерү предметы булып ведомство буйсынуындагы

оешманың оештыру-хокукый формасын билгели торган документларындагы белешмәләр, ведомство буйсынуындагы оешма вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары, ведомство буйсынуындагы оешма эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен үтәүгә бәйле документлар тора.

2. Документар тикшерү җирле үзидарә органы урнашкан урын буенча уздырыла.

3. Документар тикшерү барышында җирле үзидарә органы вазыйфаи затлары тарафыннан ведомство карамагындагы оешманың документлары, элек үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында документлар (алар булганда) карала. Җирле үзидарә органының вазыйфаи затлары тарафыннан документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документлар соратып алынырга мөмкин. Соратуда күрсәтелгән документлар ведомство буйсынуындагы оешманың җитәкчесе яисә башка вазыйфаи затының имзасы һәм мөһер (булганда) белән таныкланган күчермәләр рәвешендә бирелә.

## VII. Күчмә тикшерү үткәрү

7.1. Күчмә тикшерү предметы булып ведомство буйсынуындагы оешма документларындагы белешмәләр, шулай ук аның эшчәнлеге хезмәт законнарына һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларга туры килү-килмәве, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен үтәү буенча гамәлгә ашырылучы чаралар тора.

7.2. Күчмә тикшерү ведомство карамагындагы оешманың урнашу һәм (яки) эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

7.3. Күчмә тикшерү документар тикшерү белән түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта уздырыла:

1) җирле үзидарә органы карамагындагы ведомство буйсынуындагы оешманың документларында булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә;

2) ведомство буйсынуындагы оешма эшчәнлегенең хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен, ведомство буйсынуындагы оешма урнашкан урынга һәм (яисә) аның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урынына барып, өстәмә чаралар үткәрмичә бәяләргә.

7.4. Ведомство буйсынуындагы оешма күчмә тикшерү үткәрүче вазифаи затларга күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметлары белән бәйле документлар белән танышу, шулай ук оешма карамагында булган биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне тикшерү мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.

7.5. Җирле үзидарә органы ведомство буйсынуындагы оешманы күчмә тикшерүгә экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итәргә хокуклы. Экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен түләү, шулай ук ведомство контроле чараларында катнашуга бәйле рәвештә чыгымнарны каплау дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда экспертлар һәм эксперт оешмалары чыгымнарын каплау өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте

тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә башкарыла.

7.6. Күчмә тикшерү тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт таныклыкларын күрсәтүдән һәм ведомствога караган оешма вәкилен күчмә тикшерү билгеләү турында җирле үзидарә органының тиешле хокукый актының күчермәсе белән мәҗбүри таныштырудан башлана.

## VIII. Тикшерү үткәрү срогы

8.1.Тикшерү үткәрү срогы 20 эш көненнән арта алмый.

8.2. Махсус экспертиза һәм (яисә) тикшерүләр уздыруның кирәклегенә бәйле аерым очракларда, тикшерү уздыра торган вазыйфаи затларның нигезле тәкъдиме нигезендә, күчмә планлы тикшерүне үткәрү срогы җирле үзидарә органының тиешле хокукый акты белән озайтылырга мөмкин, әмма 20 эш көненнән артмаган срокка.

## IX. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

9.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү уздыручы вазыйфаи затлар тарафыннан акт (алга таба - тикшерү акты) төзелә (2 нче кушымта), анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) тикшерү үткәргән җирле үзидарә органының исеме;

3) тикшерү үткәрү турында җирле үзидарә органы хокукый актының датасы һәм номеры;

4) тикшерү уздырган вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерүне үткәргән экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булган очракта) һәм вазыйфалары;

5) тикшерелә торган ведомство буйсынуындагы оешманың исеме, шулай ук тикшерү үткәргәндә катнашкан ведомство буйсынуындагы оешма вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм вазыйфасы;

6) тикшерү уздыру датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозулар турында, аларның характеры турында һәм күрсәтелгән хокук бозуларга юл куйган затлар турында белешмәләр;

8) тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның имзалары;

9) тикшерү үткәргәндә катнашкан ведомство буйсынуындагы оешма вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яисә танышудан баш тартуы турында, аның имзасы булу яисә имза салудан баш тартуы турында белешмәләр.

9.2. Тикшерү актына үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яки бәяләмәләре, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозган өчен җаваплылык йөкләнгән ведомство буйсынуындагы оешма хезмәткәрләренең аңлатмалары һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.

9.3. Тикшерү акты, тикшерү тәмамланганнан соң, ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән ведомство карамагындагы оешма

вәкиленә алу кәгазе (расписка) белән тапшырыла.

9.4. Дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны үз эченә алган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

9.5. Хезмәт законнары таләпләрен һәм хезмәт хокукы нормалары үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозу ачыкланган очракта, аларны бетерү өчен вакыт тикшерү актында яисә җирле үзидарә органының хокукый актында күрсәтелә.

## X. Тикшерү нәтиҗәләре буенча күрелә торган чаралар

10.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесе билгеләнгән срокларда хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозуны бетерүне тәэмин итәргә тиеш.

10.2. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча күрелгән чаралар турында хисап алга таба эшчәнлектә ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны бетерү срогы чыккан көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча җирле үзидарә органына тапшырыла. Күрсәтелгән хисапка хокук бозуларны бетерүне раслый торган документларның һәм материалларның күчермәләре кушымта итеп бирелә. Җирле үзидарә органы ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту чараларын күрергә тиеш.

10.3. Ачыкланган хокук бозулар бетерелмәгән яисә ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесенең аларны бетерүдән баш тарткан очракта, җирле үзидарә органы гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартуга юнәлдерелгән чаралар күрә.

## XI. Ведомство контролен гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи затлары гамәлләренә шикаять бирү тәртибе

11.1. Ведомствога буйсынучы учреждение җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тикшерү уздырган ҖҮО вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата, тикшерү актын алган көннән алып 15 календарь көн эчендә ҖҮО җитәкчесенә шикаять белдерергә хокуклы.

11.2. Шикаять администрациягә кәгазь чыганакта язма рәвештә яки шикаять төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырыла.

11.3.Шикаять үз эченә ала:

1) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган администрация вазыйфаи затларының фамилиясен, исемен, атасының исемен;

2) ведомство буйсынуындагы учреждение исеме;

3) ведомство буйсынуындагы учреждениене гамәлгә куючы булып торучы җирле үзидарә органы исеме;

4) администрация вазыйфаи затларының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

5) мөрәҗәгать итүченең алар нигезендә ҖҮО вазыйфаи затларының карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган дәлилләре. Гариза бирүче мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар тапшырырга мөмкин.

11.4. Шикаять администрациядә теркәлү датасыннан 30 календарь көннән дә артмаган срокта ҖҮО җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан карала.

11.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавап ведомство буйсынуындагы учреждение җитәкчесенә (җитәкче урынбасарына) язма рәвештә кәгазь чыганакта яки ҖҮО җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында җибәрелә.

11.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча җавапта күрсәтелә:

1) ҖҮО атамасы, шикаять буенча карар кабул иткән вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) карар кабул итүнең номеры, датасы, урыны;

3) карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелгән ҖҮО вазыйфаи затларының вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме;

4) шикаять буенча кабул ителгән карар;

5) шикаять нигезле дип танылган очракта - шикаять буенча карар кабул итү датасыннан 30 календарь көннән артмаска тиешле ачыкланган хокук бозуларны бетерү сроклары;

6) шикаять буенча кабул ителгән карар нигезе.

11.7. Җирле үзидарә органы түбәндәге очракларда шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта:

1) шул ук предмет турындагы һәм шул ук нигезләрдә шикаять буенча законлы көченә кергән суд карары булганда;

2) шул ук мөрәҗәгать итүчегә карата һәм шул ук шикаять предметы буенча элек кабул ителгән шикаять буенча карар булганда;

3) әгәр шикаять вәкаләтләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган зат тарафыннан бирелгән булса.

1 нче кушымта
Хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында Нигезләмәгә

**Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүне 20___ елда планлаштырылган тикшерүләр уздыруның еллык планы**

| N т/б | Муниципаль учреждение исеме, ИНН, КИП | Муниципаль учреждениегә карата гамәлгә куючының функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимият органы исеме | Муниципаль учреждениенең юридик (факттагы) адресы | Эшчәнлегенең тикшерелә торган чоры | Тикшерү үткәрүнең датасы (ае) | Тикшерү үткәрүнең срогы (эш көннәрендә) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

2 нче кушымта
Хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында Нигезләмәгә

**Тикшерү акты**

_______________ "__" _______________ 20__ ел
(актны төзү урыны)

_______________________________________________

(муниципаль учреждениенең исеме)
хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә
Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясы, 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының _____________ N ___________________
"_______________________________________________ күрсәтмәсе нигезендә
(тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәнең исеме)
"
20__ елның "__" ___________нан 20__ елның "__" _______________кадәр чорда
_______________________________________________

_______________________________________________тарафыннан

(тикшерү үткәргән администрациянең вазыйфаи затларының вазыйфалары, фамилияләре, инициаллары)
хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле кысаларында
_______________________________________________ карата

_______________________________________________тикшерү ҮТКӘРЕЛДЕ.
(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)

_______________________________________________

(муниципаль учреждениенең иялек килешендәге исеме)
ИНН _________________________, КПП ________________________________, аңа карата гамәлгә куючының функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы
_______________________________________________

(башкарма хакимият органының баш килешендәге исеме)
юридик адресы:
_______________________________________________

Эшчәнлекне фактта гамәлгә ашыру урыны адресы (адреслары) :
_______________________________________________

20__ елның "__" __________нан 20__ елның "__" __________на кадәр чорда
Тикшерү үткәрү турында күрсәтмәнең күчермәсе белән
_______________________________________________

_______________________________________________

(тикшерелгән муниципаль учреждениенең вазыйфаи затлары вазыйфалары,

фамилияләре, инициаллары)

______________________________________________________________________

таныштырылды 20__ елның "__" _____________.

Тикшерү ______________________________________________________________

(тулысынча, сайлап)

тикшерүнең методы белән түбәндәге документлар: ____________________________________________

_______________________________________________________________________тикшерелде

(тикшерелгән документларның исеме һәм реквизитлары күрсәтелә)

Тикшерү барышында ачыкланды __________________________________________

______________________________________________________________________

(хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны ачыкланган хокук бозулар, бозылган нормаларга, хокук бозуларның характерына, күрсәтелгән хокук бозуларга юл куйган затларга сылтама белән күрсәтелә яки хокук бозуларның ачыкланмавы турында тамга ясала)

Ачыкланган бозуларны түбәндәге срокларда бетерергә тәкъдим итәбез:

______________________________________________________________________

(бозуларны бетерү сроклары күрсәтелә)

һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына аларны бетерү турында хисапны түбәндәге срокларда тапшырырга: ______________________________.

(хисап бирү срогы күрсәтелә)

Ведомство буйсынуындагы учреждение җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тикшерү үткәргән, "Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлеге башкарма комитетының вазыйфаи затларына тикшерү үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмауга) карата «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының җитәкчесенә, тикшерү актын алган датадан 15 календарь көн эчендә шикаять бирергә хокуклы.

Тикшерү актына кушымталар:

1)

______________________________________________________________________

2)

______________________________________________________________________

3)

______________________________________________________________________

________________________________________

(администрациянең тикшерү үткәргән

________________________________________ __________/______________________/

вазыйфаи заты вазыйфасы атамасы) (имза) (инициаллары, фамилиясе)

Тикшерү актының нөсхәсе бирелде: ____________________________________

______________________________________________________________________

(тикшерелгән муниципаль учреждениенең вазыйфаи затлары вазыйфалары, фамилияләре, инициаллары һәм имзалары)

"__" ___________ 20__ ел.